**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2022 елның 4 апрелендәге ПУ-233 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 7 июнендәге ПУ-400 номерлы, 2022 елның 31 августындагы ПУ-611 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 3 апрелендәге 194 номерлы һәм 2024 елның 6 ноябрендәге 852 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Әлеге Указда куелган максатларда, махсус хәрби операция барган вакытта ирекле рәвештә хәрби бурычлар үтәгән гражданнар дигәндә, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы (Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәте) тарафыннан Россия Федерациясе Президенты карары белән төзелгән ирекләләр формированиеләренә керүләре турында Россия Федерациясе Оборона министрлыгы (Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәте) белән контракт төзегән гражданнар күздә тотыла.».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 7 июненнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 18 ноябрь
№ 892